ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

**(V чакырылыш)**

Чираттан тыш утырыш

«25» декабрь 2025 ел № 7 Олы Мишә ав.

**«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының 11.05.2021 № 26 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Олы Мишә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының 11.05.2021 № 26 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Олы Мишә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (18.08.2023 № 89, от 20.10.2023 № 93, 08.2.2024 №105 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Олы Мишә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәдә:

А) 9 статьяның 6 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә **бәян итәргә**:

«-Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://tulachi.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

Теләче муниципаль районы
Олы Мишә авыл җирлеге башлыгы: Ф.Б.Җамалетдинов